СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Ташкичү авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«02» апрель 2026 ел** **№ 13**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында" 2022 елның 25 февралендәге 2 нчы номерлы карарына (2023 елның 11 декабрендәге 16 нче номерлы, 2024 елның 5 ноябрендәге 14 нче номерлы, 2025 елның 18 нчы ноябрендәге 6 нче номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Ташкичү авыл җирлеге"" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Ташкичү авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында" 2022 елның 25 февралендәге 39 нчы номерлы карары (2023 елның 11 декабрендәге 16 нче номерлы, 2024 елның 5 ноябрендәге 14 нче номерлы, 2025 елның 18 нчы

ноябрендәге 6 нче номерлы үзгәрешләр белән белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 1.7 бүлегенең 1.7.1 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“5) контрольдә тотыла торган затның үз-үзен җайга сала торган оешмада мәҗбүри әгъза булуы каралган булса, контрольдә тотыла торган затларның, аларның вәкилләренең, ә контрольдә тотыла торган затларның, аларның вәкилләренең ризалыгы белән Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең яисә аның иҗтимагый вәкилләренең, Россия Федерациясе субъектында эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең контроль (күзәтчелек) чаралары (аларны үткәргәндә контроль (күзәтчелек) органнарының контрольдә тотылучы затлар белән үзара эшчәнлеге таләп ителми торган контроль (күзәтчелек) чараларыннан тыш) үткәргәндә катнашуына комачауламаска һәм 248-ФЗ номерлы Федераль законда һәм әлеге Нигезләмәнең 3.4 бүлегендә каралган очракларда консультацияләр бирүне гамәлгә ашырырга;»;

**1.2. 3.5.1 бүлегенең 1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“2) “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә тапшырган контрольдә тотылучы затларга яисә билешмәләре классификацияләнгән чаралар реестрына кертелгән контрольдә тотылучы затларга карата. Мондый хәбәрнамәләр тапшырыла торган эшмәкәрлек эшчәнлеге төрләре исемлеге контроль төре турындагы нигезләмә белән раслана. Күрсәтелгән очракта мәҗбүри профилактик визит мондый хәбәрнамә тапшырылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча

үткәрелә;»;

**1.3. 3.5.1 бүлегенең 1 өлешендәге 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“в) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (гамәлгә ашыру вәкаләтләре гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә, федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә һәм 248-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда муниципаль контроль төрләренә карата).”;

**1.4. 3.5.1 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::**

“3. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый. Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында тикшереп торучы затка ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.”;

**1.5. 3.5.1 бүлегенең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“6. Әгәр боерыкта контроль төре һәм (яисә) контрольдә тотылучы затлар исемлеге күрсәтелмәгән булса, мондый йөкләмәне үтәүне оештыру максатларында 248-ФЗ номерлы Федераль законның 52_1 статьясындагы 7 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары боеерыгы кабул ителә.”;

**1.6. 3.5.2 бүлекнең 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:**

“5) контрольдә тотылучы зат әлеге бүлекнең 1 пунктында каралган критерийларга туры килми.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин